**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам противодействия коррупции

В связи с изменениями в федеральном законодательстве по вопросам противодействия коррупции **постановляю:**

1. Внести в Положение о представлении гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 30 декабря 2009 года № УП-702 «О представлении гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711, от 16 мая 2012 года № УП-343, от 22 апреля 2013 года № УП-328, от 24 сентября 2014 года № УП-920, от 23 марта 2015 года № УП-308, от 13 октября 2015 года № УП-988, от 18 марта 2016 года № УП-265, от 11 февраля 2017 года № УП-123 и от 11 декабря 2017 года № УП-1092), следующие изменения:

а) дополнить пунктом $9^1$ следующего содержания:

«$9^1$. Сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера представляются по утвержденной Президентом Российской Федерации форме справки, заполненной с использованием специального программного обеспечения «Справки БК», размещенного на официальном сайте Президента Российской Федерации, ссылка на который также размещается на официальном сайте федеральной государственной информационной системы в области государственной службы в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».»;

б) пункт 15 изложить в следующей редакции:

«15. Сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленные в соответствии с настоящим Положением гражданином или кандидатом на должность, включенную в Перечень должностей, сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемые гражданским служащим ежегодно, а также информация о результатах проверки достоверности и полноты этих сведений приобщаются к личному делу гражданского служащего. Указанные сведения также могут храниться в электронном виде.

В случае если гражданин или кандидат на должность, включенную в Перечень должностей, представившие в кадровую службу государственного органа Республики Татарстан справки о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также справки о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруги (супруга) и несовершеннолетних детей, не были назначены на должность гражданской службы, такие справки возвращаются указанным лицам по их письменному заявлению вместе с другими документами.».

2. Внести в Положение о представлении гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 11 января 2010 года № УП-4 «О представлении гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан, сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о представлении лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 мая 2012 года № УП-343, от 22 апреля 2013 года № УП-330, от 20 августа 2014 года № УП-797, от 24 сентября 2014 года № УП-920, от 23 марта 2015 года № УП-308 и от 18 марта 2016 года № УП-265), следующие изменения:

а) дополнить пунктом $8^1$ следующего содержания:

«$8^1$. Сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера представляются по утвержденной Президентом Российской Федерации форме справки, заполненной с использованием специального программного обеспечения «Справки БК», размещенного на официальном сайте Президента Российской Федерации, ссылка на который также размещается на официальном сайте федеральной

государственной информационной системы в области государственной службы в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».»;

б) абзац первый пункта 14 изложить в следующей редакции:

«14. Сведения о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленные в соответствии с настоящим Положением лицом, замещающим государственную должность Республики Татарстан, при назначении (избрании, утверждении) на должность, а также сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемые им ежегодно, и информация о результатах проверки достоверности и полноты этих сведений приобщаются к личному делу лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан. Указанные сведения также могут храниться в электронном виде.».

3. Внести в Положение о проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, и соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711 «О проверке достоверности и полноты сведений, представляемых гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан, и соблюдения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан требований к служебному поведению» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 мая 2012 года № УП-343, от 6 ноября 2013 года № УП-1084, от 24 сентября 2014 года № УП-920, от 23 марта 2015 года № УП-308, от 13 октября 2015 года № УП-988 и от 11 декабря 2017 года № УП-1092), изменение, изложив пункт 21 в следующей редакции:

«21. На период проведения проверки гражданский служащий может быть отстранен от замещаемой должности государственной гражданской службы Республики Татарстан (от исполнения должностных обязанностей).

На период отстранения гражданского служащего от замещаемой должности государственной гражданской службы Республики Татарстан (от исполнения должностных обязанностей) денежное содержание по замещаемой им должности сохраняется.».

4. Внести в Положение об Управлении Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 31 января 2011 года № УП-37 «Об утверждении Положения об Управлении Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 26 июля 2013 года

№ УП-693, от 3 декабря 2013 года № УП-1176, от 20 августа 2014 года № УП-797, от 13 октября 2015 года № УП-987 и от 2 декабря 2017 года № УП-1042), следующие изменения:

а) пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3. Управление в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, указами и распоряжениями Президента Российской Федерации, постановлениями и распоряжениями Правительства Российской Федерации и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, Законом Республики Татарстан от 4 мая 2006 года № 34-ЗРТ «О противодействии коррупции в Республике Татарстан», иными законами Республики Татарстан, указами и распоряжениями Президента Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, решениями Совета при Президенте Российской Федерации по противодействию коррупции и его президиума, принятыми в пределах их компетенции, а также настоящим Положением.»;

б) в абзаце четвертом пункта 8 слова «повышения квалификации и стажировки» заменить словами «профессионального развития»;

в) в пункте 10 слова «, в том числе сведений, касающихся частной жизни граждан и должностных лиц или затрагивающих их честь и достоинство» исключить.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания, за исключением пунктов 1 и 2, которые вступают в силу с 1 июля 2020 года.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
04 марта 2020 года
№ УП-137

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча федераль законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2017 елның 11 февралендәге ПУ-123 номерлы һәм 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пунктны өстәргә:

«$9^1$. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында, шулай ук керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган, Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган «Белешмәләр БК» махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган белешмә формасында тапшырыла, аңа таяну өчен мәгълүмат шулай ук «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтындагы дәүләт хезмәте өлкәсендә бирелә.»;

б)15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан яисә Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфа биләүгә кандидат тарафыннан бирелгән керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләр, шулай ук граждан хезмәткәре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында ел саен бирелүче белешмәләр, шулай ук әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә. Әлеге белешмәләр шулай ук электрон рәвештә сакланырга мөмкин.

Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәтенә үзләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр биргән граждан яисә Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфа биләүгә кандидат граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелмаган очракта, бу белешмәләр әлеге затларга аларның язма гаризасы нигезендә башка документлар белән бергә кире кайтарып бирелә.».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-330 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы һәм 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пунктны өстәргә:

«$8^1$. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында, шулай ук керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган, Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган «Белешмәләр БК» махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган белешмә формасында тапшырыла,

аңа таяну өчен мәгълүмат шулай ук «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтындагы дәүләт хезмәте өлкәсендә бирелә.»;

б) 14 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан, вазыйфага билгеләп куелганда (сайланганда, расланганда) керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында бирелгән белешмәләр, шулай ук аның тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында ел саен бирелә торган белешмәләр һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның шәхси эшенә теркәлә. Әлеге белешмәләр шулай ук электрон рәвештә сакланырга мөмкин.».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы һәм 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә, 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«21. Тикшерү уздыру чорында граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә биләгән вазыйфасыннан (хезмәт вазыйфаларын башкарудан) читләштерелергә мөмкин.

Граждан хезмәткәрен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә биләгән вазыйфасыннан (хезмәт вазыйфаларын башкарудан) читләштерү чорына аның биләгән вазыйфасы буенча акчалата түләү саклана.».

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-37

номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-987 номерлы һәм 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларына һәм боерыкларына һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасының башка законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, Коррупциягә каршы көрәшү буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Советның һәм аның президиумының карарларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.»;

б) 8 пунктның дүртенче абзацында «квалификация күтәрү һәм стажировка узу» сүзләрен «һөнәри үсеш» сүзләренә алмаштырырга;

в) 10 пункттагы «, шул исәптән гражданнарның һәм вазыйфаи затларның шәхси тормышына яисә аларның намусына һәм кешелек дәрәҗәсенә кагылышлы мәгълүматларны» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. Әлеге Указ, 2020 елның 1 июленнән үз көченә керәчәк 1 һәм 2 пунктлардан кала, аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 04 март
№ ПУ-137